| ГЛАВА<br>Кадыбашского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Кадыбаш авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 Кадыбаш № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2021 елның 30 ноябрендә 13 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2021 елның 30 ноябрендә 14 сәг 30 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Кадыбаш авылының Клубная, Яшьләр, Гали урамнарында яшәүчеләр.

-2 этап: Кадыбаш авылының Совет, Подгорная, Касай урамнарында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Кадыбаш авылында скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрен ремонтлау;

2. Кадыбаш авылында урамнарны яктырту чаралары

(урам яктырткычларын,электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алмаштыру һәм хезмәт шартнамәсе буенча электрик өчен түләү);

3. Кадыбаш авылында урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү,үләннәрне чабу, дизель ягулыгы сатып алу, кардан чистарту, Кадыбаш авылында тракторга дизель мае алу, хезмәт килешүе буенча тракторчыга түләү);

4. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү, янгын сүндерү машинасына бензин сатып алу, запас частьлар сатып алу);

5. Кадыбаш авылында Гали урамына бара торган юл өслеге өчен ком һәм вак таш сатып алу, төяү, каплау, юл салу;

6.Кадыбаш авылы территориясендә хуҗасыз йортларның фасадларын алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу һәм башкарылган эшләр өчен хезмәт килешеүе буенча түләү)

- фасадларның тышкы төрләрен төзекләндерү һәм ремонтлау, торак йортларның коймаларын булдыру һәм төзелеш материаллары сатып алу;

7. МТЗ тракторы өчен асылма җиһазлар сатып алу.

8. 3 штук бензочапкыч, 2 штук бензопычкы, бензин һәм май сатып алу,агачлар кисү,үләннәрне чабу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадыбаш ав., Клубная, 49б йорт адресы буенча авыл клубында үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Х.Л.Закиров